


# Рәмис Аймәт

**Рәмис Кыяметдин улы Айматов 1968елның 4 октябрендә Чүпрәле районы Мочали авылында туа. Авылда сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач, Иске Чүпрәле урта мәктәбендә укый һәм урта белемгә ия булып, Казан дәүләт университетында югары белем ала. Аны тәмамлагач, “Шәһри Казан” газетында эшли, Татарстан язучылар берлеге рәисенең урынбасары була. Аннан Казандагы Шәриф Камал музее директоры, бер үк вакытта “Шәһри Казан” газетында әдәби хезмәткәр, соңыннан Габдулла Тукай музее директоры вазыйфаларын башкара.**

**2000 елда шагыйрьнең “Шомырт салкыннары”исемле беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыкты. Бу китап турында гади китап укучылар гына түгел, республикабызның әдәбият һәм сәнгать әһелләре, әдәбият галимнәре дә уңай фикерләрен белдерделәр.**

...Бу дөньяга яралганмын
Яшеннәрнең, ахры, утлы күз яшеннән.
Бер мизгелдә гүя күкләр колы булдым-
Йөрәгемә тамыр җәйде яшеннәр...



# Бер елмаю эзлим…

**Мин елмаю эзлим кешеләрдән,**
**Ера-ера хаклык ташкынын.**
**Юар өчен җанны каплап алган**
**Күңел төпләренең юшкынын.**

**Мин елмаю эзлим чын йөрәктән,**
**Чын күңелдән кайнап чыкканын.**
**Салкын кизләү кебек бикерактан**
**Челтер-челтер килеп акканын.**

# Җирсү

**Туган якта таңнар һаман дамы,**
**Һаман дамы ата алсуланып?**
**Мин генә ул йөрим  еракларда,**
**Алсу таңнар кебек моңсуланып.**

**Мин генә ул “Кайтам,кайтам!..”дим дә,**
**Вәгъдәсезлек.Кайтып булмый шул гел.**
**Туган якның офыгында һәркөн**
**Рәшә булып бии минем күңел.**

# Табигатькә мәдхия

Табигатькә каршы барам,
Мин-табигать җимеше.
Йә мин аның бер чишмәсе,
Йә кечкенә инеше.

Агам һаман җырлый-җырлый,
Моңнарым тынмас кебек.
Каршыма җилләр иссә дә,
Күңелем тынмас кебек.

# Китәсең...

**Язлар булып килеп кергән идең,**
**Көзләр булып китеп барасың.**
**Ерагая бара , ерагая**
**Безнең мәхәббәтнең арасы.**

**...Көзләр булып китеп барасың син,**
**Соңгы яфрак кебек талпынып.**
**Йөрәгемдә минем дөрләп яна**
**Көзге усакларның ялкыны.**

# Син

Син мине кабат тудырдың,
Син миңа бирдең канат.
Бозга әйләнгән җанымны
Назыңа төрдең кабат.

Йөзәмен наз дулкынында
Язын да,кышын да мин.
Богаудагы бер колың да,
Хөр, азат кошың да мин.

**Бу җырларым сезгә бүләк булсын,**
**Канат бирсен сезгә яшәргә.**
**Йөрәкләргә сагыш уралса да,**
**Яшеннәрдәй кирәк яшьнәргә.**

**Җыр яктыртсын барыр юлыгызны,**
**Чакырып торсын яңа зур үрләр.**
**Бу дөньялар һәрчак җырлы булсын,**
**Җырлы булсын безнең гомерләр.**

